ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.01.2019 Балык Бистәсе штп. № 43пи

"Балык Бистәсе муниципаль районы архив бүлеге тарафыннан архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү" дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре күрсәтүне оештыру турында" 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма Комитетының 2013 елның 19 ноябрендәге "Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең яңа редакциядәге исемлеген раслау турында" 231пи номерлы карары, 2016 елның 21 июнендәге "Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибе турында"96пи номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. "Балык Бистәсе муниципаль районы архив бүлеге тарафыннан архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү" дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентын яңа редакциядә расларга (кушымта).

2. Көчен югалткан дип танырга:

Башкарма комитетның 2012 елның 29 июнендәге 173пи номерлы карары белән расланган "Балык Бистәсе муниципаль районы архив бүлеге тарафыннан архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү" үзидарәлек хезмәте күрсәтү Административ регламентын.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 1 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында" 107пи номерлы карарының 8 пунктын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлегенә йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2019 елның 29 гыйнварындагы
43 пи номерлы карарына
кушымта

**Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ Регламенты архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: физик затлар, юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче, гариза бирүче).

1.3. Дәүләт хезмәте Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә (алга таба – Башкарма комитет).

Дәүләт хезмәтен башкаручы – Башкарма комитетның Архив бүлеге (алга таба – Бүлек).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: РТ, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт.

Бүлекнең урнашу урыны: РТ, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт.

Башкарма комитетның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе 08:00 дән 17:30 га, җомга 08:00 дән 17:00 гә кадәр, төшке аш 12:00 дән 13:30 га хәтле. Бүлекнең эш графигы :

Дүшәмбе – җомга 8.00 дән 17.30 га кадәр.

Шимбә, якшәмбе – ял.

Төшке аш 12:00 дән 13:30 га хәтле.

Халыкны һәм юридик затларны кабул итү:

Дүшәмбе – җомга 08.30 дан 12.00 гә чаклы;

Керү (үтү) – шәхесне таныклаучы документ буенча.

1.3.2. Бүлекнең белешмә телефоны: (84361) 2-39-57 .

1.3.3. Башкарма комитетның Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – “Интернет” челтәре) рәсми сайтының адресы: http://www. balyk-bistage@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Бүлекнең урнашу урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүматны алырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен үзидарәлек хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны эченә алган Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) “Интернет” челтәре ярдәмендә:

Башкарма комитетның “Интернет” челтәрендәге http://www. balyk-bistage@tatar.ru. рәсми сайтында;

Татарстан Республикасының https://uslugi.tatarstan.ru дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр Порталында;

http:// www.gosuslugi.ru Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр (функцияләр) порталында.

3) Башкарма комитетка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон буенча);

4) язма рәвештә (шул исәптән электрон документ рәвешендә) Башкарма комитетка мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Башкарма комитетның рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Үзидарәлек хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” №131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба №131-ФЗ номерлы Федераль закон ) (РФ законнары җыентыгы, 2003, № 40, 3822 маддә);

2004 елның 22 октябрендәге “Россия Федерациясендә архив эше турында” 125-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 125-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 25.10.2004, № 43, 4169 маддә);

2010 елның 27 июлендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ законнары җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 маддә);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 15 июнендәге “Башкарма хакимиятнең федераль органнарында Эш башкару кагыйдәләрен раслау турында” 477 номерлы карары (алга таба – Эш башкару кагыйдәләре) (Российская газета, № 4937, 24.06.2009);

2015 елның 31 мартында Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 526 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм үзидарәлек архивларындагы, музейлардагы һәм китапханәләрдәге, Россия Фәннәр академиясе оешмаларындагы башка архив документларын саклау, туплау, исәпкә алу һәм файдалануны оештыру Кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр);

Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Законы (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Татарстан Республикасы, 03.08.2004, №155-156);

Татарстан Республикасының 2007 елның 24 декабрендәге “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының архив эше өлкәсендәге аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 63-ЗРТ номерлы Законы (алга таба – ТР ның 2007 елгы 63-ЗРТ номерлы Законы) (Татарстан Республикасы, 2007 ел, 25 декабрь, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасының 2017 елның 20 июлендәге “ Татарстан Республикасында архив эше турында” 63-ЗРТ номерлы Законы (алга таба – ТР ның 63-ЗРТ номерлы Законы);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 28 маендагы “Муниципаль берәмлекләр оешканчы, берләшкәнче, бүленгәнче яки аларның статусы үзгәргәнче төзелгән һәм Татарстан Республикасының муниципаль архивларында саклана торган архив документларына милек чикләве турында” 203 номерлы карары (алга таба – ТР МК ның 203 номерлы карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 13.06.2007, № 22, 0803 маддә);

Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы;

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә (алга таба – Башкарма комитеты турында Нигезләмә);

Башкарма комитет тарафыннан 2016 елның 23 сентябрендә 69ри номерлы карар белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге турында Нигезләмә (алга таба – бүлек турында Нигезләмә);

2015 елның 21 гыйнварындагы 04 ри номерлы Боерык белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре.).

1.5. дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дигәннән (алга таба - гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсенең 2 п.) аңлашыла. Гариза билгеләнгән үрнәк буенча яки стандарт бланкта ирекле рәвештә тутырыла.

Гариза стандарт бланкта электрон рәвештә тутырыла:

Башкарма комитетның рәсми сайтында (http://www.balyk-bistage@tatar.ru);

Татарстан Республикасының дәүләт һәм үзидарәлек порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/);

дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең (функцияләрнең) Бердәм порталында (http:www.gosuslugi.ru/).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп исеме | Стандартка таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәте яки таләпне тәгаенләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте исеме | Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү | 125-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.2. Турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимиятнең муниципаль органы исеме | Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты. Дәүләт хезмәтен башкаручы - Башкарма комитетның Архив бүлеге . | 125-ФЗ номерлы Федераль законның 4 маддәсе 5 өлеше; Архив бүлеге турында Нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Соратыла торган мәгълүматларның булуы һәм урнашу урыны буенча консультация бирү | 125-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.4.Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә[1] | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә гариза бирүче тапшырырга тиешле зарури документларның, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрнең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать (шәхсән кабул ителүдә яки телефон буенча, Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайты аша электрон документ рәвешендә, факсимиль язма мөрәҗәгать).<br>Шәхсән кабул ителүдә граждан шәхесен таныклаучы документын күрсәтә | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 19 маддәсенең 1 өлеше |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә зарур булган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хаклы документларның тулы исемлеге. | Әлеге категориягә кертелергә мөмкин булган документларны бирү таләп ителми | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда күздә тотылган очракларда килештерүләре дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителә | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |

[1] Биредә һәм алга таба процедураларның дәвамлылыгы эш көннәре белән исәпләнә

| | | |
|---|---|---|
| һәм мондый килештерү дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирле үзидарә органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләренең тулы исемлеге | Документларны кабул итүне кире кагу каралмаган | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган<br>Кире кагу өчен нигезләр:<br>1. Мөрәҗәгатьнең асылы буенча элек җавап бирелгән булса.<br>2. Документларның урнашу урыны турында мәгълүматлар булмау | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | 125-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсенең 3 өлеше;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 8 маддәсенең 1 өлеше |
| 2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | 125-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсенең 3 өлеше;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 8 маддәсенең 1 өлеше |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гарызнамә биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Гарызнамә биргәндә һәм нәтиҗәне алганда дәүләт хезмәтен алучының (мөрәҗәгать итүченең) кабул ителүен көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләре өчен чиратлылык билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында | Гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне | Эш башкару кагыйдәләренең IV |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итүченең гарызнамәсен теркәү срогы | | кисәгенең 16 пункты |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтеп тору һәм гариза бирүчеләрне кабул итү урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларга инвалидлар өчен үтүне тәэмин итүгә, андый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бина һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидларга муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз килү тәэмин ителә (биналарга уңайлы керү-чыгу һәм алар эчендә күчenү).<br>Муниципаль хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләргә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып. | |
| 2.15.Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре | Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>-Бүлек бинасының җәмәгать транспорты үтәрлек зонада булуы;<br>-белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыра торган бүлмәләрнең кирәкле санда булуы;<br>-мәгълүмат стендларында, “Интернет” челтәрендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүматның булуы.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән сыйфатлана:<br>-гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү һәм бирүдә чиратларның;<br>-дәүләт хезмәте күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) | |

| | | |
|---|---|---|
| | шикаятьләрнең;<br>-дәүләт хезмәте күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата нәзакәтсезлегенә, илтифатсызлыгына шикаятьнең. | |
| 2.16. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза электрон документ рәвешендә түбәндәге электрон адрес буенча җибәрелергә мөмкин:<br>E-mal: balyk-bistage@tatar.ru | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 19 маддәсенең 1 өлеше |
| 2.17. Күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәтен күрсәтү үзенчәлекләре | Күпфункцияле үзәктә (алга таба - КФҮ) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә консультация бирүне, документларны кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара. | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсе |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча мәгълүмат җыю;

4) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 1 номерлы кушымтада рус телендә бирелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү

Гариза бирүче дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультация алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон буенча һәм/яки язма рәвештә, шул исәптән электрон почта буенча мөрәҗәгать итә.

Бүлек белгече гариза бирүчегә консультация бирүне гамәлгә ашыра, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутыруда булышлык күрсәтә.

Әлеге пунктта тәгаенләнгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү.

3.3. архив документларының урнашу урыны мәсьәләләре буенча мәгълүмат җыю

3.3.1. Гариза бирүче (аның вәкиле) Бүлекнең урындагы затына кабул итү вакытында яки телефоннан шәхсән телдән мөрәҗәгать итү рәвешендә язма рәвештә кәгазь йөрткечтә, электрон рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләре порталы аша яисә почта аркылы, факс буенча гариза тапшыра (юллый).

3.3.2. Бүлек белгече гаризаны терки.

Әлеге пунктта тәгаенләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән мизгелдән соң 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза.

3.3.3. Бүлек белгече:

документларның архивта булу-булмавын тикшерә;

кирәкле документлар архивта булмаган очракта документларның урнашу урынын керү мөмкин булган мәгълүматлар базаларыннан эзләүне гамәлгә ашыра;

документларның урнашу урынын тәгаенләгәннән соң язма рәвештә (факс буенча), электрон хәбәрләр рәвешендә, телдән хәбәр рәвешендә кабул итү вакытында яки телефоннан документның урнашу урыны хакында гариза бирүчегә кирәкле мәгълүматларны хәбәр итә;

Архивта документ булган очракта архив белешмәсен (архив өземтәсен, архив документларының күчермәләрен) бирү турында мөрәҗәгать итүчегә гариза (язма рәвештә яки электрон документ рәвешендә) тутырырга тәкъдим итә.

Әлеге пунктта тәгаенләнгән процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә документларның урнашу урыны буенча консультация бирү.

3.4. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү

3.4.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу өчен КФҮ кә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.4.2. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү билгеләнгән тәртиптә расланган КФҮ нең эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.4.3. Дәүләт хезмәтен алуга КФҮтән документлар килеп ирешкәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе КФҮ кә җибәрелә.

**4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контроль тәртибе һәм формалары**

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгына һәм сыйфатына контроль гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылуын ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының үтәлүенә тикшерүләр уздыруны, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешенә контроль формалары булып тора:

дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларына хокукый экспертиза уздыру. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларга виза салу тора;

делопроизводствоны алып баруга билгеләнгән тәртиптә уздырылучы тикшерүләр;

дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларын үтәүгә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарәнең ярты еллык һәм еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга тиешле) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләрне үткәргәндә дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле бөтен сораулар да (комплекслы тикшерү) каралырга мөмкин яисә гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча планнан тыш тикшерүләр үткәрелә.

4.2. Үзидарәлек хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контроль Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (ул вәкаләт биргән зат) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи регламентлар турындагы нигезләмәләр белән билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу ачыкланган очракта гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Бүлек башлыгы әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ процедураларны вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә Бүлек эшчәнлегенең ачыклыгы ярдәмендә, үзидарәлек хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

**5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе**

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Башкарма комитет хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Башкарма комитетка, Башкарма комитет җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата муниципаль берәмлек Советына судка кадәр тәртиптә шикаять белдерү хокукына ия.

КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелә.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәнең теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогын бозу;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль район норматив хокукый актлары тарафыннан тәкъдим итү яисә гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүматларны яисә гамәлләр кылуны таләп итү;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль район норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүне кире кагу;

5) федераль законнар һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль район норматив хокукый актларында кире кагуга нигезләр күздә тотылмаган булуга карамастан, дәүләт хезмәте күрсәтүне кире кагу;

6) дәүләт хезмәте күрсәтүдә гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль район норматив хокукый актларында күздә тотылмаган түләүне таләп итү;

7) ) Башкарма комитетның, Башкарма комитетның урындагы затының, КФҮ нең, КФҮ хезмәткәренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүне кире кагуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын яисә тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актларда дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатуга нигезләр күздә тотылмаган булуга карамастан, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату (туктатып тору);

10) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны яки мәгълүматны баштагы кабул итүдәге кире кагуда юклыгы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны дәүләт хезмәте күрсәтүдә, 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 7 маддәсе 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан гайре, гариза бирүчедән таләп итү.

Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять бирү шул очракта мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган күпфункцияле үзәккә тиңдәшле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 16 маддәсенең 1.3 өлеше белән тәгаенләнгән тәртиптә тулы күләмдә йөкләнгән булса.

11) дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган баштагы кабул итүдәге кире кагуда юклыгы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны бирүне яки, түбәндәге очраклардан тыш, дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән таләп итәргә хаклы түгел:

а) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза башта бирелгәннән соң дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актлар таләпләре үзгәрү;

б) дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне баштагы кире

какканнан соң мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документларда, яисә дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдә һәм элек тәкъдим ителгән документлар комплектына кертелмәгән документларда хаталар булу;

в) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне баштагы кире кагудан соң яки дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүдә документларның гамәлдә булу вакыты чыгу яки мәгълүмат үзгәрү;

г) ) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның урындагы затының яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, әлеге Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешма хезмәткәренең дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне баштагы кире кагуда яисә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә ялгыш яки хокукка каршы гамәл кылуының (гамәл кылмавының) документаль расланган факты (билгеләре) ачылу, кайсыдыр ки ул турыда дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәк җитәкчесенең дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне баштагы кире кагуда яисә әлеге Федераль законның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган оешма җитәкчесенең имзасы белән язма рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәрнамә ирештерелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен кичерү сорала.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь йөрткечтә, электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүче Башкарма комитетка, КФҮ кә бирелә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче Башкарма комитет җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр муниципаль берәмлек Советына бирелә.

КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүче Башкарма комитетның, дәүләт хезмәте күрсәтүче Башкарма комитетның урындагы затының, үзидарәлек хезмәткәренең, дәүләт хезмәте күрсәтүче Башкарма комитет җитәкчесенең карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта белән, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең ераклашкан эш урыны аша “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Балык Бистәсе муниципаль берәмлегенең рәсми сайтын (http://www. balyk-bistage@tatarstan.ru), Татарстан Республикасының дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең Бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru/), дәүләт һәм үзидарәлек хезмәтләренең (функцияләренең) Бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итүдә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның урындагы затының яки үзидарәлек хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең исемен;

2) гариза бирүченең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булганда), тору урыны турында мәгълүматларны – физик затның яисә гариза бирүченең исеме, урнашу урыны турында мәгълүматларны – юридик затның, шулай ук гариза бирүчегә җавап җибәрү өчен контакт телефоны номерын (номерларын), электрон почта адресын (адресларын) (булганда) һәм почта адресын;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, КФҮ, КФҮ хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматларны;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән гариза бирүченең риза булмавына нигез булып торган дәлилләрне.

5.4. Шикаятьне карау срогы – аның теркәлгән көненнән соң унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органның урындагы затының (учреждение хезмәткәренең), КФҮ нең мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүне яисә җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтүне кире кагуга шикаять яки андый төзәтүләрнең билгеләнгән срокларын бозуга шикаять бирү очрагында – теркәлгән көннән соң биш эш көне дәвамында.

5.5. Шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре шикаятькә теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә теркәлгән документларның исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның кайсы да булса берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү яки үзидарәлек хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хата һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, үзидарәлек хокукый актларында түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүне кире кагу.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көн артыннан килүче көннән дә соңга калмыйча гариза бирүчегә язма рәвештә һәм аның теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле дип табылу очрагында 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 11.2 маддәсе 8 өлешендә күрсәтелгән гариза бирүчегә җавапта муниципаль хезмәт күрсәткәндә беленгән бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, КФҮ тарафыннан тормышка ашырылучы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен кичерү сорала һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне алу максатларында гариза бирүчегә кылу зарур булган алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип табылу очрагында 27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 11.2 маддәсе 8 өлешендә күрсәтелгән гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре хакында дәлилле аңлатмалар бирелә, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.8. Шикаятьнең канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип табылу очрагында гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре хакында дәлилле аңлатмалар бирелә, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре табылу очрагында шикаятьләрне карау буенча вәкаләтләр бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрәләр.

Кушымта № 1

РФ______________________________муниципаль берәмлеге ТР Балык Бистәсе муниципаль районы ___________________________________
архив бүлегенә
___________________________________-тан (-дан)
_____________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, почта индексы, адрес, электрон адрес – гарызнамәне электрон почта аша юллаганда)

архив документларының урнашу урыны
мәсьәләләре буенча консультация бирү турында

**Г А Р И З А**

____________еллар өчен ____________________________________________адресы буенча урнашкан _______________________________________________________буенча

(оешманың, бүлекнең, цехның,бригаданың, торак пунктның исеме)


документларның урнашу урыны турында мәгълүматларны хәбәр итүегезне үтенәм.
Документлар түбәндәгеләр турында архив белешмәсе (күчермәсе, өземтәсе) алу өчен кирәк:

_______________________________________________ еллар өчен стаж турында
________________________________________________еллар өчен хезмәт хакы турында
_________________________________________________еллар өчен уку турында
_________________________________________________еллар өчен башка турында
Мөрәҗәгать итүченең телефоны __________________________________________________

____________________ ____________ _____________________________________
(дата) (имза) (ФИАи)

Кушымта №2

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы *(рус телендә)*



Кушымта (белешмә)

Архив документларының урнашу урыны
мәсьәләләре буенча консультация бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы
урындагы затларның реквизитлары
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының
Архив бүлеге

| Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Бүлек башлыгы | (884361)<br>2-39-57 | Farid.Hasanov@tatar.ru |
| Бүлек белгече | 2-39-57 | |

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты

| Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | (884361)<br>2-25-00 | balyk-bistage@tatar.ru |